Республика Татарстан
**СОВЕТ МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Советская, д. 47, с. Муртыш-Тамак
423358
Телефон: 4-52-05

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 47 йорт, Мортыштамак авылы,
423358
Телефон: 4- 52-05

РЕШЕНИЕ                                                                 КАРАР

№ 2                                                                 14.02.2022 елның

Советның 2021 елның 25 ноябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл жирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елнын 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы 2021 елның 25 ноябрендәге 13 номерлы Совет карары белән расланган нигезләмәләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 «Сарман муниципаль районы территориясендә торак контроле өчен индикатив күрсәткечләр исемлеге» карарына 3 нче кушымтаны расларга (кушымта итеп бирелә);

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге
Советы Рәисе                                                                 И. Н.Һадиуллин

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

**Муниципаль контроль (күзәтчелек) индикатив күрсәткечләре исемлеге**

1) хисап чорында үткәрелгән планлы контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
3) мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга контроль объектының туры килүен ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан читкә тайпылуы нигезендә хисап чорында үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
4) хисап чорында уздырылган үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;
5) хисап чорында уздырылган һәр контроль (күзәтчелек) чаралары төре буенча үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;
8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;
9) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;
12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;
13) прокуратура органнарына хисап чорында килештерүдән баш тарткан контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында җибәрелгән гаризалар саны;
14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;
15) куркыныч категорияләренә кертелгән контроль объектларының һәр категориясе буенча хисап чоры ахырына исәпкә алынган объектларының саны;
16) хисап чоры ахырына контрольдә торучы затларның саны;
17) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә торучы затлар саны;
18)хисап чорында контрольдә торучы затлар тарафыннан суд тәртибендә җибәрелгән контроль (күзәтчелек) органнары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерү турында дәгъвалар саны;

19)контрольдә торучы затлар тарафыннан хисап чорында белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән суд тәртибендә җибәрелгән контроль (күзәтчелек) органнары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерү турында дәгъвалар саны;

20) муниципаль контрольне (күзәтчелекне) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне җитди бозу белән үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яисә) хисап чорында юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.